СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
«20» декабрь 2023 ел

КАРАР
№ 108

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү» турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы (соңгы үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 88.89.90 статьялары нигезендә, Чепья авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында «, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан урманнардан, махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.3. 5 статьяның 1 өлешендәге 21 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 7 статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясе субъектларының» сүзләрен «Татарстан Республикасының» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 7 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы « Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы Федераль закон белән җайга салына.»;

1.6. 12 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдумны оештыру һәм тәэмин итү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

1.7. 13 статьяның 3 өлешендәге өченче абзацында «Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссияләре» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 14 статьяның 5 өлешендә «җирлек сайлау комиссиясенә» сүзләрен « федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп оештырылган (алга таба - сайлау комиссиясе) сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 14 статьяның 8 өлешендә «Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 14 статьяның 12 өлешендә «Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.11. 17 статьяның 9 өлешендә «(җирлек Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.12. 19 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пунктының старостасы авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча җирлек советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пунктының старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары яки җыен тәкъдим иткән көнгә 18 яше тулган һәм әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

1.13. 19 статьяның 3 өлешендә «муниципаль хезмәт вазыйфасын» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыра торган муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

1.14. 19 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «муниципаль вазыйфаны» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

1.15. 19 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл торак пунктының старостасы вәкаләтләре авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме белән җирлек Советы карары буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 10 өлешенең 1 - 7 пунктларында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.»;

1.16. 19 статьяның 6 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) әлеге Устав һәм (яисә) җирлек Советының норматив хокукый акты белән каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны Татарстан Республикасы

законы нигезендә гамәлгә ашыра.»;

1.17. 19 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Эшчәнлек гарантияләре һәм авыл торак пункты старостасы статусының башка мәсьәләләре әлеге Устав һәм (яисә) Советның норматив хокукый акты белән Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнергә мөмкин.»;

1.18. 25 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.19. 25 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Җирлек составына керә торган торак пункт территориясе өлешендә һәм торак пункт территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы законы нигезендә;»;

1.20. 25 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлешенең чикләре җирлек әһәмиятендәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бердәмлеге критериеннән чыгып билгеләнә.»;

1.21. 32 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында «дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставында билгеләнә һәм тулаем алганда аена икедән ким һәм алтыдан да күбрәк эш көне була алмый» » сүзләрен «дәвамлылыгы бер айда алты эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

1.22. 32 статьяның 6 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук, түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә катнашырга:

а) сәяси партия , һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез идарә итүдә катнашу , иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсе белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәри берлек оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш), Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башлыгына (Рәис) алдан хәбәр итеп;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә

органнарында җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) гамәлгә куючы оешманың вәкаләтләрен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталының өлеше) белән җирлек исеменнән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга нигезләнеп, гамәлгә куючысы җирлек булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

1.23. 32 статьяның 9 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)" сүзләренә, «җирле үзидарә депутаты» сүзләрен «депутат» сүзенә алмаштырырга;

1.24. 32 статьяның 10.1 өлешендә «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә, «җирле үзидарә депутаты» сүзләрен «депутат» сүзенә алмаштырырга;

1.25. 32 статьяның 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җирлек Советы депутаты,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә,әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне ,шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса.»;

1.26. 32 статьяның 12 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

1.27. 33 статьяның 5 өлешендә «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.28. 34 статьяның 1 өлешендә «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.29. 35 статьяның 1 өлешендәге 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.30. 42 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, чит дәүләт гражданлыгы яисә РФ гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирүче РФ гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы туктатылса, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

1.31. 42 статьяның 2 өлешендә «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы» сүзләрен «Җирлек советы» сүзләренә алмаштырырга;

1.32. 42 статьяны түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеше белән тулыландырырга:

«2.1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре, депутат нигезле сәбәпләрсез җирлек Советының барлык утырышларында алты ай рәттән булмаган очракта,

җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

1.33. 42 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн дип,җирлек Советына шушы гариза кергән көн санала.»;

1.34. 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Җирлек башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны, чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә,әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне ,шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса.»;

1.35. 46 статьяның уникенче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.36. 47 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47 статья.Җирлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу

1. Җирлек башлыгының вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китсә;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага китсә;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфасыннан ваз кичсә;

5) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылса;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

7) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә керсә;

8) Россия Федерациясе чикләреннән даими яшәү урынына чыкса;

9) чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга, чит дәүләт гражданлыгы яисә РФ гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирүче РФ гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы туктатылса, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынса;

11) суд тәртибендә сәламәтлеге торышы буенча җирлек башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга ныклы сәләтсез дип билгеләнсә;

12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.1-1, 3.2, 3.3, 4 - 6.2, 7 - 7.2 өлешләре нигезендә җирлек үзгәртеп корылса; шулай ук җирлек бетерелсә;

13) шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә җирлек муниципаль берәмлек статусын югалтса;

14) Җирлек чикләре үзгәрү яисә җирлекнең шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә сайлаучылар саны 25 проценттан да артса;

15) халыкның турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозылса;

16) « Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне, бурычларны үтәмәгән очракта;

2. Җирлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлек башлыгын сайлау вәкаләтләр шул рәвешле туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта әгәр җирлек Советының вәкаләтләр чоры тәмамланганчы алты айдан кимрәк вакыт калган булса, муниципаль берәмлек башлыгын җирлек советы составыннан сайлау яңа сайланган Җирлек Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.

3. Җирлек башлыгы Татарстан Республикасы башлыгының (Рәисенең) хокукый акты нигезендә вазифасыннан ваз кичкән яки җирлек башлыгын отставкага җибәрү турында җирлек Советы карары нигезендә җирлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлек башлыгы әлеге хокукый акт яисә суд карарына шикаять бирсә, суд карары көченә кергәнче, җирлек Советы җирлек башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә тиеш түгел.";

1.37. 51статьяның 1өлешенең 4 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыра;»;

1.38. 51статьяның 1 өлешенең 4 пунктындагы җиденче абзацында «гомуми файдаланудагы һәм аларның яр буе полосаларындагы» сүзләрен өстәргә;

1.39. 51статьяның 1 өлешнең 4 пунктындагы сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыра;";

1.40. 51статьяның 1 өлешенең 4 пунктындагы тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип таныргa;

1.41. 51статьяның 1 өлешнең 5 пунктындагы бишенче абзацында «билгеләнгән таләпләр белән туры килүгә» сүзләрен «рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларына, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килүенә» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.42. 51статьяның 1 өлешенең 7 пунктының икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.43. 51статьяның 1 өлешенең 7 пунктындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга,җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга, мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалау һәм үстерүгә юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;»;

1.44. 51статьяның 1 өлешенең 9 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ритуаль хезмәтләр оештыруны һәм күмү урыннарын карап тотуны тәэмин итә;»;

1.45. 51 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктының тугызынчы абзацында «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.46. 51 статьяның 2 өлешендәге өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.47. 51 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законы белән җайга салына.»;

1.48. VII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

1.49. 69 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.50. 69 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «йә күрәләтә дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү йә, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;

1.51. 69 статьяның 2 өлешендә «,федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.52. Уставның 72 статьясы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «77 статья. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актларның, килешүләрнең үз көченә керү һәм бастырып

чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе»

1.53. Уставның 77 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр басма массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында (htpp://pravo.tatarstan.ru) яисә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (htpp://baltasi.tatarstan.ru) рәсми рәвештә игълан ителгәннән һәм мәгълүмат стендларында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.»;

1.54. Уставның 77 статьясындагы 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актны яисә килешүне рәсми бастырып чыгару дип, аның тулы текстын муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугат басмасында беренче бастырылып чыгару яисә аның тулы текстын челтәр басмасында беренче тапкыр урнаштыру санала.»;

1.55. 77 статьяга түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарылудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турындагы белешмәләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге район башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».

1.56. 89 статьяның 7 өлешендәге өченче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.57. 89 статьяның 21 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

1.58. 88 статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.59. 88 статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында «(вәкиллекле орган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы гражданнар җыены карары белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.60. 93 статьяның 3 өлешендә «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә. 5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин